ГЛАВА
КУТЛУ-БУКАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422665, с.Кутлу-Букаш.
ул.Советская , дом 32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КОТЛЫ БӨКӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422665, Котлы Бөкәш авылы
Совет урамы, 32 йорт

Тел.: (84361) 31521, факс: (84361) 31642, e-mail: Kbuk.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 07 ноябрендә Котлы Бөкәш авылы № 4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Котлы Бөкәш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 25 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

3. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, көндезге формада белем алучы студентлардан , тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1) кышкы юлларны кардан чистарту;

2) урам утларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;

3) Тәберде Чаллысы авылын су белән тәэмин итү системаларына хезмәт күрсэтү;

4) авыл урамнарына сатып алынган вак ташны җәю;

5) вак таш тигезләү өчен трактор хезмәтләренә түләү;

6) Тәберде Чаллысы авылы өчен чүп контейнерлары сатып алу.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

4. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

5. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов